ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

Х. Такташа ул., 94, а/я 44, Казань, 420107

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ һӘМ АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮНЕ,
ӘЙЛӘНЕШТӘ ЙӨРТҮНЕ,
СЫЙФАТЫН ДӘҮЛӘТ ТИКШЕРҮЕН
ТӘЭМИН ИТҮ һӘМ КУЛЛАНУЧЫЛАР
ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь инспекциясе)

һ.Такташ урамы, 94 нче йорт, Казан шәһәре, 420107

тел. (843) 278-92-00, факс (843) 278-91-92, e-mail: cla@tatalc.ru, http://www.tatalc.ru,
ОКПО 42151664, ОГРН 1021602865239, ИНН/КПП 1654025044/165901001

_______________ № _______________

На № ___________ от _______________

# БОЕРЫК

20.07.2016 Казан ш. №12-07/48

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 23.05.2016 ел, №12-08/39 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне легаль булмаган җитештерүне һәм әйләнештә йөртүне ачыклауга ярдәм иткән гражданнарга матди түләүләрне хәл итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы территориясендә этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне җитештерү һәм әйләнештә йөртү өлкәсендә закон бозу фактлары турында хәбәр иткән гражданнарны матди яктан кызыксындыру максатыннан чыгып, БОЕРЫК БИРӘМ:

1. “Гражданнарны матди яктан кызыксындыру турында” 23.05.2016 ел, №12-08/39 Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне җитештерү һәм әйләнештә йөртү өлкәсендә закон бозу фактлары турында хәбәр иткән гражданнарга матди түләүләрне хәл итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.5. Вәкаләтле вазыйфаи зат түбәндәге документларның берсен: административ хокук бозу урынын карау беркетмәсен; административ хокук бозу турында эшне тикшерүне тәэмин итү чараларын куллану турында беренче беркетмә; административ хокук бозу турында эш кузгату хакында билгеләмә; административ хокук бозу турында беркетмә төзүгә

килү турында уведомление (извещение); административ хокук бозу турында беркетмә; сәүдә объектын сүтү турында документ тутырганда (чыгарганда), Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең контрольлек-инспекция бүлеге белгече югарыда санап үтелгән документларның берсе тутырылганнан соң (чыгарылганнан соң) өч тәүлектән дә соңга калмыйча заявкасын карап тикшерү йомгаклары буенча югарыда санап үтелгән документларның берсе тутырылган (чыгарылган) мөрәҗәгать итүче белән, мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (uslugi.tatarstan.ru) шәхси кабинетын теркәгәндә күрсәткән телефон номеры яки электрон почта адресы буенча, мөрәҗәгать итүче белән элемтәгә керә. Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүчегә, матди түләү турында гариза тапшыру өчен,үзенең яшәү урынына якын булган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе территориаль органына мөрәҗәгать итү тәкъдим ителә.”;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4.1. Түләү бу Тәртипнең 3.5 пунктында күрсәтелгән документларның берсе булганда яки җинаять эше кузгату турында карар булганда хәл ителә.”;

4.3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“бу Тәртипнең 3.5 пунктында күрсәтелгән документлар арасыннан берсенең күчермәсе;”;

4.7.1пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“- бу Тәртипнең 3.5 пунктында күрсәтелгән документларның берсе булганда һәм 100 литрдан артыграк күләмдә этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне законсыз әйләнештән алганда, расланылган закон бозу факты турында заявка өчен.”;

4.7.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4.7.2. 2000 сум күләмендә:

- юридик затка карата тутырылган, бу Тәртипнең 3.5 пунктында күрсәтелгән документларның берсе булганда, расланылган закон бозу факты турында заявка өчен;

- бу Тәртипнең 3.5 пунктында күрсәтелгән документларның берсе булганда һәм 10нан 100 литрга кадәрге күләмдә этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне законсыз әйләнештән алганда, расланылган закон бозу факты турында заявка өчен;

- бу Тәртипнең 3.5 пунктында күрсәтелгән документларның берсе булганда, алкогольле продукцияне ваклап сату буенча расланылган лицензиясез эшчәнлек факты турында заявка өчен.”;

4.7.3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“- бу Тәртипнең 3.5 пунктында күрсәтелгән документларның берсе булганда расланылган закон бозу факты турында заявка өчен.”.

1.2. Татарстан Республикасы территориясендә этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне легаль булмаган җитештерүне һәм әйләнештә йөртүне ачыклауга ярдәм иткән гражданнарга матди түләүләрне хәл итү тәртибенә №1 кушымтаны, бу боерыкка кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Хокук бүлегенә (Б.Г.Эйдинов) бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасары Р.А.Арслановка йөкләргә.

Җитәкче И.А.Марченко

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең
20.07.2016 ел, №12-07/48
боерыгына кушымта

“Татарстан Республикасы территориясендә этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне легаль булмаган җитештерүне һәм әйләнештә йөртүне ачыклауга ярдәм иткән гражданнарга матди түләүләрне хәл итү тәртибенә №1 кушымта

“Халык контроле” дәүләт мәгълүмат системасына алынган мөрәҗәгатьләрнең учетын алып бару журналы формасы

| № п/п | Заявканы “Халык контроле” дәүләт мәгълүмат системасына урнаштыру номеры һәм датасы | Мөрәҗәгать итүче турында мәгълүматлар | Заявканың асылы | Адресы | Территориаль органга җибәрү датасы | Заявканы карап тикшерү турында мәгълүмат (контрольлек чарасын үткәрү датасы, нәтиҗәсе) | Тартып алынган алкогольле яки спиртлы продукция күләме | Тәртипнең 3.5 пунктында күрсәтелгән документларны тутыру турында мәгълүмат | Матди түләү турында мәгълүмат (мөрәҗәгать итүченең Ф.И.О., матди түләүне алу датасы һәм суммасы)” |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|